КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 сентябрь г.Казань № 829

2019 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен;

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2017 ел, 23 сентябрь, 713 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 22 сентябрь, 829 нчы
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәт күрсәтүләр исеме | Норматив чыгымнар, бер берәмлеккә 1 елга сум | 1 елга хезмәт күрсәтүләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Архив белешмә кәгазь-ләрен, архив күчермәләрен, архив өземтәләрен, граж-даннарның законлы хокук-ларын һәм ирекләрен тор-мышка ашыру һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле мәгълүмат хатларын бирү | 755,57 | 20 000 | үтәлгән соратып алулар саны, берәмлек |
| 2. | Архивның уку залында архив документларыннан һәм аларның белешмә алу өчен эзләү чараларыннан файдалана алу мөмкин-леген тәэмин итү | 749,14 | 8 000 | уку залына керүләр саны, берәмлек |

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 22 сентябрь, 829 нчы
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архив документлары белән комплектлау | 10 100 149 |
| 2. | Архив документларының сакланышын тәэмин итү һәм аларны исәпкә алу | 19 919 394 |
| 3. | Архив документларының тасвирламасын эшләү, аларның белешмә алу өчен эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә характерындагы мәгълүмат бирү басмаларын әзерләү | 4 971 576 |
| 4. | Архив документларындагы дәүләт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итә торган мәгълүматларны саклау һәм аларның сер булуын билгеләнгән тәртиптә бетерүне оештыру | 3 394 987 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәнең документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм методик ярдәм күрсәтү | 3 010 398 |
| 6. | Архив документларының белешмә алу өчен эзләү чараларыннан “ерактан торып” файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 3 324 337 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат чараларын, бастырып чыгару һәм күргәзмә проектларын тормышка ашыру | 5 952 057 |

_________________________________